Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Ленино-Кокушкино авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлеге Ленино Кокушкино авылы Кояшлы, Казан урамнары гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

15 октябрь, 2024 ел № 1

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлеге Ленино Кокушкино авылы Кояшлы, Казан урамнары гражданнарының 2024 елның 15 октябрендәге җыены беркетмәсе нигезендә түбәндәгеләр ачыкланды:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм гражданнар җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 35 (утыз биш).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнарның гомуми саны 20 (егерме).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 20 (егерме).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 0 (ноль).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча «Сез 2025 елда Ленино Кокушкино авылы Кояшлы, Казан урамнары территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 5000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- торак пункт (Кояшлы ур.) чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту» **кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Ленино-Кокушкино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

Ленино-Кокушкино авыл җирлеге башлыгы А.Р. Сәйфетдинов